БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
17 июль 2024ел

**КАРАР**
№ 263

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы "Салавыч авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Салавыч авыл җирлеге территориясенең шәһәр төзелешен планлаштыруны гамәлгә ашыру максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 32 статьясына, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14,15 статьяларына, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставына таянып, гавами тыңлаулар һәм килештерү комиссиясе нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Балтач район Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2023 елның 09 февралендәге 167 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы "Салавыч авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә, түбәндәге редакциядә бәян итеп, кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Салавыч авыл җирлеге башкарма комитетына:

- шәһәр төзелеше эшчәнлеген әлеге карарның 1пункты белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы “Салавыч авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре нигезендә гамәлгә ашырырга;

- Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы "Салавыч авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турындагы карарын территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасына йөкләүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi. tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

Балтач муниципаль районы башлыгы урынбасары,
Балтач район Советы рәисе урынбасары Н.Н.Сабирҗанов